ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 21 ноябре №_2_

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**Карар:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хәрби операциягә киткән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз)сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
1) Дружба торак пунктыны чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, традицион күмү урыннарына кадәр юлларны вак таш белән каплау (махсус техника, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдерлау);

2) Дружба торак пунктында урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы карап тору (шартнамә буенча лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы ______________ Ю.Г.Антонов